СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » февраль 2022 ел** **№ 123**

**«Арча муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 декабрендәге 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Арча район Советы карар бирде:

«Арча муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 97 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Арча муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге»нә 4 нче кушымта өстәргә (кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
28 февраль 2022 ел, № 123
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге**

1) хисап чорында уздырылган планлы контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

2) хисап чорында уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читкә тайпылуы нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

4) хисап чорында үзара хезмәттәшлектә үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында һәр контроль (күзәтчелек) чара төре буенча үзара хезмәттәшлектә үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларыннан файдаланып уздырылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

7) хисап чорында уздырылган мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын уздыруны килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм аларны прокуратура органнары килештерүдән баш тарткан гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына куркынычлылык категориясенең һәркайсы буенча куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларының

саны;

16) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган контроль (күзәтчелек) чаралар уздырылган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы карау срогын бозган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъвалар саны;

20) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының алар буенча игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) дәгъвалау турында суд тәртибендә җибәрелгән дәгъвалар саны;

21) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру таләпләрен тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны.